ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 7** **2 апрель 2021 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты 24.02.2021 ел, № 5 “Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законы, 2020 елның 1 апрелендагы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында»гы 69-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты 24.02.2021 ел, № 5 “Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Тәртипнең 2.4 пунктында “күрсәтмәләр” сүзен “карарлар” сүзенә алмаштырырга;

1.2. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциягә бәян итәргә:

“3.Башкарма комитет ягыннан капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү шартлары”;

1.3. Тәртипнең 3.1 пунктының 6) пунктчасын түбәндәге редакциягә бәян итәргә:

6) “административ-эшлекле үзәкләрне һәм сәүдә үзәкләрен (комплексларны), шулай ук күп фатирлы йортларны, торак йортларны(территорияләрне комплекслы үстерү турында килешү нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).”

1.4. Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 4нче пункт өстәргә:

“4.Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге,әгәр дә мондый килешүнең ягы булып, тиешле инвестицион проект гамәлгә ашырыла торган Татарстан

Республикасы булса, капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү яклары булырга мөмкин.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында, Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев